РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

№ 3

2022 елның 4 феврале

## Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Матди ярдәм шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләрнең тулы вәкаләтле вәкилләре арасында төзелгән территориаль-тармак социаль партнерлык килешүендә каралган нигезләр буенча да түләнергә мөмкин.»;

6 пунктта:

1 пунктчада «50» санын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2» санына алмаштырырга;

5 пунктчада:

өченче абзацта «35» санын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга;

9 пункттa:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкасы» сүзләрен «айлык тариф ставкасының бер бөтен уннан сигезе» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

2. Түбән Кама муниципаль район Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарының 5 пунктындагы беренче абзацы әлеге карар редакциясендә 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль район Советының социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

А.В.Умников